**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 2 апрель № 214

г. Казань

Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтү турында

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, шулай ук Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтү тәртибен;

Гражданнарның түләүсез теш протезлары һәм колак аппаратлары ясауга хокуклы аерым категорияләре төбәк регистрын тапшыру буенча Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы арасында мәгълүмат алмашу тәртибен.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 2 апрель, 214 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтү тәртибе

1. Бу Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтү тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә (алга таба – 63 нче Закон) нигезендә түләүсез теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәте күрсәтү хезмәтләре рәвешендә Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә адреслы социаль ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыру кысаларында эшләнде.

2. Бу Тәртиптә түбәндәге төшенчәләр файдаланыла:

социаль ярдәм чараларын тормышка ашыру максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә колак аппаратлары ясауны техник чаралары белән түләүсез тәэмин итү хезмәтләре күрсәтү;

теш протезлары һәм теш протезларын түләүсез һәм колак аппаратларын түләүсез гамәлгә ашыручы медицина оешмасы – бу Тәртипне тормышка ашыруда катнашучы һәм тиешле медицина эшчәнлегенә лицензиясе булган медицина оешмасы.

3. Татарстан Республикасы Законы нигезендә түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак аппаратлары ясау гражданнарның түбәндәге категорияләренә гамәлгә ашырыла:

«Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсиягә хокук бирә торган яшькә җиткән хезмәт ветераннарына;

1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәр биш елда кимендә алты ай тылда эшләгән затларга, СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләгән чорны кертмичә, Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнгән затларга;

тернәкләндерелгән гражданнарга;

сәяси репрессияләрдән зыян күргән гражданнарга;

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга, «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсиягә хокук бирә торган яшькә җиткәч.

Татарстан Республикасы законнары нигезендә түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак аппаратлары ясатуга хокуклы гражданнарның аерым категорияләре

төбәк регистрын (алга таба – төбәк регистры) алып бару Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтүче медицина оешмалары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен раслана торган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәме түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасы белән билгеләнә.

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы Татарстан Республикасы законнары нигезендә түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак аппаратлары ясауга хокуклы гражданнарга әлеге хезмәтләрне күрсәтүне гамәлгә ашыручы медицина оешмалары турында хәбәр итә.

5. Түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак аппаратлары ясауга хокуклы гражданнарны аерым категорияләренә күрсәтелә торган түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак аппаратлары ясау күрсәтү исемлеге бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.

Түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак аппаратлары ясау бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча рәсмиләштерелгән көтү кәгазе нигезендә билгеләнгән чират буенча башкарыла.

6. Түләүсез теш протезлары (колак аппаратлары) ясауга хокуклы һәм төбәк регистрага кертелгән гражданнар хезмәт күрсәтүдән файдалану өчен медицина оешмаларына мөрәҗәгать иткәндә шәхесләрен таныклый торган документ күрсәтә.

7. Бу Тәртипне тормышка ашыру кысаларында түләүсез теш протезлары яки түләүсез колак аппаратлары ясау алдыннан граждан «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 ел, 21 ноябрь, ФЗ-323 нче Федераль законның 20 статьясы таләпләре нигезендә медицина чарасын күрүгә үз теләге белән риза булуын рәсмиләштерә.

8. Бу Тәртипне тормышка ашыру максатларында ясалган ремонтны гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

9. Бу Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән гражданнарны аерым категорияләрен колак аппаратлары белән тәэмин итү алар колак аппаратларына мохтаҗ дип табылган шартларда гамәлгә ашырыла.

10. Түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак аппаратлары ясау буенча хезмәтләр күрсәтүче медицина оешмалары бу Тәртипне тормышка ашыру кысаларында түбәндәгеләрне тәэмин итә:

түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак аппаратлары ясауга хокуклы гражданнарның аерым категорияләре төбәк регистрына кертелгән гражданнарга теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтүне;

билгеләнгән форма буенча теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтүгә көтү кәгазе алып барыла;

төбәк регистрын саклауны һәм ай саен яңартуны;

адреслы социаль яклауга хокуклы гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары (колак аппаратлары) ясау хезмәтләре күрсәткән өчен түләүгә Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган бертип форма буенча Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды белән шартнамә төзүгә;

теш протезлары һәм колак аппаратлары хезмәте күрсәтүне исәпкә алып баруны;

хисап аеннан соң килүче айны бишеннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына кәгазь чыганакта хисап аенда күрсәтелгән теш протезлары (колак аппаратлары) ясау буенча төгәлләнгән очраклар буенча исәпләп һәм исәпләрнең реестрларын, шулай ук Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды арасында тиешле елга Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программалары буенча күрсәтелгән медицина ярдәме турындагы мәгълүматларның шәхсиләштерелгән исәбен алып баруны гамәлгә ашырганда мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе нигезендә электрон файлларны (алга таба – мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе);

бу Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасында гражданнарны аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләр турында акт формасының шәхсиләштерелгән исәбен алып баруны;

билгеләнгән тәртиптә расланган түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак аппаратлары ясау буенча финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарын тиешле елга Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицинак ярдәме түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасын раслаган көннән 14 көн эчендә Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына кертүне;

Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондыннан теш протезлары һәм колак аппаратлары ясаудан кергән акчадан максатчан файдаланыла.

11. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына һәм медицина оешмаларына Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан аны алган көннән 5 календарь көн эчендә төбәк регистрын тапшыруны. Төбәк регистрын тапшыру якланган ысул белән электрон рәвештә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына вәкаләтле хезмәткәренең электрон имзасы белән гамәлгә ашырыла;

Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колек аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтүче медицина оешмаларында төбәк регистрын үз вакытында яңартуны тикшерүдә тотуны;

тез протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтүне оештыруны һәм аларны күрсәтү чираты тәртибен.

12. Түләүсез теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәте күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан ел саен социаль ярдәмгә хокуклы гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтүдә финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына тапшырыла торган бюджетара трансфертлары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

13. Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды түбәндәгеләрне тәэмин итә:

медицина оешмалары белән адреслы социаль яклауга хокуклы гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары (колак аппаратлары) ясау хезмәтләре күрсәтүгә ясау өчен Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган бертип форма буенча шартнамәләр төзүгә;

медицина оешмаларына теш протезлары (колак аппаратлары) ясау хезмәтләре күрсәтүне планга күләменең айлык кыйммәтенең 30 проценты күләмендә Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджетына бу максатларга трансфертлар кергән шартларда агымдагы айның 20 кадәр аванс бирүне;

медицина оешмалары күрсәтелгән теш протезлары (колак аппаратлары) ясау хезмәтләренә түләүгә медицина оешмалары керткән исәпләргә медицина-икътисадый экспертиза һәм медицина-икътисадый тикшерү үткәрүне;

гражданнарның аерым категорияләренә медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелгән теш протезлары (колак аппаратлары) хезмәтләре күрсәткән өчен түләү Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджетында әлеге максатларга акча булган шартларда һәм үткәрелгән медицина-икътисадый тикшерү һәм медицина-икътисадый экспертиза нәтиҗәләре буенча финанслау корректировкасы суммаларын һәм элек түләнгән аванс суммаларын исәпкә алып түләүгә исәпләп һәм исәпләү реестрлары нигезендә һәр айның 10сына кадәр түләүне;

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына һәр айның 15 еннән дә соңга калмыйча теш протезларын (колак аппаратлары) ясау хезмәтләре күрсәтүдән файдаланган затлар турында хисап елының 1 гыйнварыннан мәгълүматлар тапшыруны. Әлеге мәгълүматны тапшыру бу Тәртипкә теркәлгән 4 нче кушымтада күрсәтелгән форматта электрон рәвештә яклаланган ысул белән Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына вәкаләтле хезмәткәре электрон имзасы белән гамәлгә ашырыла;

агымдагы финанс елында файдаланылмаган бюджетара трансфертларны Татарстан Республикасы бюджетына кайтаруны.

14. Түләүсез теш протезлары һәм түләүсез колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтүгә тарифлар Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджетына мәҗбүри медицина иминияте системасы аша медицина оешмалары нигездән берканаллы финанслауны тормышка ашыруга бирелә торган бюджетара

трансфертлар исәбеннән күрсәтелгән медицина ярдәменә түләү тәртибе һәм тарифлап билгеләп турындагы тариф килешүе белән раслана.

Теш протезлары ясау хезмәте кыйммәте тарифына дәүләт идарәсе секторы операцияләре классификациясенең барлык кодлары буенча, шул исәптән җиһазларны амортизацияләүгә чыгымнар (медицина оешмасы биналарына капиталь ремонтка һәм кыйммәтле металлар, металл-керамика кыйммәтенә түләү чыгымнарыннан тыш) кертелә.

Колак аппаратын сайлап алу һәм көйләү хезмәтләре күрсәтү тарифына дәүләт идарәсе секторы операцияләре классфикацияләре операциясенә барлык кодлары буенча чыгымнар (медицина оешмасы биналарына капиталь ремонт һәм колак аппаратлары сатып алу чыгымнарыннан) кертелә.

Колак аппаратын сайлап алу, көйләү һәм кую буенча медицина хезмәте кыйммәте тарифына дәүләт идарәсе секторы операцияләре классфикацияле барлык кодлары буенча чыгымнар (медицина оешмалары биналарына капиталь ремонт чыгымнарыннан тыш) кертелә. Тариф җитештерүчегә һәм торглар үткәрү нәтиҗәләре буенча колак аппараты исеменә бәйле рәвештә билгеләнә.

16. Теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтүнең план күләмен (күләмнәрен) медицина оешмалары арасында бүлү Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды системасы аша нигездә берканаллы финанслауны тормышка ашыру кысаларында медицина оешмалары күрсәткән медицина ярдәменә түләүгә тарифлар буенча комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

17. Теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау буенча күрсәтелгән хезмәтләр өчен исәпләрнең реестрларын рәсмиләштерү тәртибе, шулай ук мәгълүмат алмашуда файдаланыла торган тиешле электрон файлларның форматлары Мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибе белән билгеләнә.

18. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтүгә бирелгән акчадан медицина оешмаларының максатчан файдалануын тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

---